**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

«03» апреля 2020 с. Тюлячи № 163

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы халкы өчен 2020 елга торак хезмәтләренә тарифлар турында» 2019 елның 31 декабрендәге 759 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Торак кодексы, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2006 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы халкы өчен 2020 елга торак хезмәтләренә тарифлар турында» 2019 елның 31 декабрендәге 759 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» карарына 1 пунктның 2 абзацын түбәндәгечә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

1) «- торак урыннан файдаланган өчен (наем өчен түләү), социаль наем шартнамәләре һәм дәүләт яисә муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннарны яллаучылар өчен торак урыннан файдаланган өчен түләү күләме һәм күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап тоткан өчен түләү күләме 1 номерлы кушымта нигезендә;».

2. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты Җитәкчесенең урынбасары - территориаль үсеш һәм инвестиция эшчәнлеге бүлеге начальнигы И.Ә. Миңнегуловка йөкләргә.

Җитәкче Н.Н. Хаҗипов